СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 31 мае № 19/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 елның 16 октябрендәге 44/2 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 1 апрелендәге 49/8 номерлы үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 6 пунктның «в» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.»;

**2) 13 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы

катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча килешүләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган) акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемненнән артса, законнар белән билгеләнгән тәртиптә Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге http://drogganoye.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырыла, ә бу белешмәләр булмаган очракта, Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында аларның мөрәҗәгатьләре буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 25 августындагы 19/5 номерлы карары (27.05.2021 9/6 номерлы редакциядә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районындагы муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр бастырып чыгару өчен бирү турында тәртибенә, **3 нче пунктның «г»** пунктчасында «акцияләрне» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/6 номерлы карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров